**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Аксубай муниципаль районы
**муниципаль беремлеге**
423072 Иске Тимошка
Авылы Ленина урамы, 2'
тел. 884344 4-53-40

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Аксубаевский муниципальный район муниципальное образование**
423072 с.Старое Тимошкино
улица Ленина, 27
тел. 884344 4-53-40

ИСКЕ ТИМОШКИНО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# КАРАР

№13 «11» 10. 2021 ел

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге Башкарма комитетының «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 24.12.2018, № 12 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

**1.** Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге Башкарма комитетының «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 24.12.2018, № 12 карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 1.5. пунктының 2-10 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Регламентта дәүләт адреслы реестрын алып бару һәм федераль мәгълүмати адреслы системаны эксплуатацияләүгә бәйле кулланыла торган төшенчәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Федераль мәгълүмат системасы турында» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 28.12.2013 ел, № 443-ФЗ Федераль закон, «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 19.11.2014ел, 1221 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә төгәл яраштырып кулланыла.»;
1.2. 1.5. пунктының 11-17 абзацларын 3-9 абзацлар дип димәк санарга;
1.3. 2.6.1. пунктының 4 – 7 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «Төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы яки Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;1.4. 2.6.1. пунктының 8 пунктчасында «Башкарма комитет» сүзен «Төзелгән килешү нигезендә Башкарма комитет яисә муниципаль районның җирле үзидарә органы, Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга 1.5. 2.6.4. пунктында «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе

тарафыннан» сүзләрен «муниципаль районның җирле үзидарә органнары, башкарма комитет тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә; шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә (http://Aksubaevo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Иске Тимошкино авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе И.А.Мулеева